# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

“18” ноябрь 2025 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 ел №33-ФЗ Федераль законның 45, 69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 17 ноябрендә узган җыен нәтиҗәләре белән «Сез 2026 елда Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуына хезмәт күрсәтү (яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау өчен материаллар сатып алу, лампаларны алыштыру)эш хәм хезмәтләр өчен түләү)).

2024 елда гражданнар җыены караган, кулланылмаган үзара салым акчаларын, җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге эшләргә хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү очен су саклагычы урнаштыру) эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).”

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә **163** (йөз алтмыш) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 82 (сиксән ике) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
“Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 82 (сиксән ике) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның **0** (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

“Сез 2026 елда Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр торак пункты

территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган:

-Урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуына хезмәт күрсәтү (яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау өчен материаллар сатып алу, лампаларны алыштыру) эш һәм хезмәт күрсәтү өчен түләү)).

2. 2024 елда гражданнар җыены караган, кулланылмаган үзара салым акчаларын, җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге эшләргә хәл итүгә юнәлдерү:

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү очен су саклагычы урнаштыру) эш һәм хезмәт күрсәтү өчен түләү)) белән килешәсезме",- дигән сорауга җавап буларак, җыен карарын кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы — Филатова Ф.Ф.